# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый

актлары нигезендә үз компетенцияләре кысаларында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итәргә хокуклы.

**3 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

**4 статья. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнары кабул итү;

2) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә чаралар үткәрү күздә тотыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау, әлеге программаларның үтәлешен тикшереп тору;

2) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итү;



3) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

3. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә чаралар үткәрү күздә тотыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) Татарстан Республикасы милкендәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итү;

3) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә мониторинг үткәрү;

4) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

**5 статья. Махсус җайланмалар һәм җиһаз урнаштырылырга тиешле социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары**

Инвалидларга файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен махсус җайланмалар һәм җиһаз урнаштырылырга тиешле социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак биналары;

2) административ биналар һәм корылмалар;

3) мәдәният объектлары һәм мәдәният-тамаша корылмалары, дини биналар һәм дини йолаларны башкару урыннары;

4) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, социаль яклау, халыкка социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкны эш белән тәэмин итү объектлары һәм оешмалары;

5) сәүдә, халыкка җәмәгать һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары, кредит учреждениеләре, нотариаль эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыннары;

6) кунакханәләр (отельләр), башка вакытлыча яшәү урыннары;

7) физкультура-сәламәтләндерү, спорт биналары һәм корылмалары, ял итү урыннары, парклар, бакчалар, урман-парклар,

пляжлар һәм аларның территорияләрендәге сәламәтләндерү һәм рекреация билгеләнешендәге объектлар һәм корылмалар, аллеялар һәм җәяүлеләр өчен юллар;

8) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру рөхсәт ителә торган сәнәгать билгеләнешендәге объектлар, кече бизнес объектлары, җитештерү объектлары;

9) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү объектлары һәм корылмалары: тимер юл вокзаллары, автовокзаллар, аэропортлар, автомобиль, тимер юл, су һәм һава транспортының халыкка хезмәт күрсәтә торган башка объектлары;

10) шәһәр, шәһәр яны һәм шәһәрара транспорт элемтәсендә барлык төр транспорт станцияләре һәм тукталышлары;

11) элемтә һәм мәгълүмат биналары һәм корылмалары;

12) тротуарлар, урамнар, юллар һәм магистральләр аша чыгу урыннары.

**6 статья. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итү**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (билгеләнгән вәкаләтләре өлкәсендә), оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар Федераль закон нигезендә социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның (кресло-колялскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итәләр.

**7 статья. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итүдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре катнашуы**

1. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге турында һәм социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге чаралар хакында объектив, дөрес һәм тулы мәгълүмат алырга хокуклы.

2. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә мониторинг уздыруда катнашырга хокуклы.

**8 статья. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне тикшереп тору**

Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне тикшереп тору Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**9 статья. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге чыгымнарны финанс белән тәэмин итү**

1. Әлеге Закон нормаларын яңа төзелә торган һәм гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә үтәүгә бәйле финанс чыгымнары күрсәтелгән объектларның милекчеләренә йөкләнә.

2. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт программалары, муниципаль программалар чараларын финанслау тиешле бюджетлар, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка финанслау чыганаклары исәбенә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Законны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән үтәүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда әлеге максатларга карала торган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Федераль законнар нигезендә әлеге Закон нигезләмәләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә бары тик 2016 елның 1 июленнән генә кулланылышка тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән күрсәтелгән объектларга карата кулланыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2017 елның 23 июне
№ 41-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

# Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

*(2012 елның 17 декабрендәге 83-ТРЗ номерлы,
2013 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы,
2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы,
2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы,
2017 елның 22 июнендәге 37-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Законның җайга салу предметы төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны тәэмин итүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрдән гыйбарәт.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы түбәндәгеләргә кагылмый:

1) юридик затларның һәм гражданнарның хокукка каршы гамәлләрне булдырмый калуга, һәлакәтләрне, табигый бәла-казаларны, бүтән гадәттән тыш хәлләрне булдырмый калуга һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә, янгыннарны сүндерүгә юнәлдерелгән, гражданнарның иминлеген тәэмин итүгә яисә халыкның тормышын тәэмин итү объектларының эшләвенә бәйле кичектергесез эшләр башкаруга, оборона гамәлләрен (шул исәптән гражданнар оборонасы һәм мобилизация буенча гамәлләрне) үтәүгә, дәүләтнең оборона сәләтен һәм иминлеген тәэмин итүгә, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген саклауга, гражданнарны коткаруга, аларның гомеренә яисә сәламәтлегенә янауны бетерүгә юнәлдерелгән гамәлләренә;

2) юридик затларның һәм гражданнарның тиешле конфессияләрнең канун таләпләре кысаларында дини йолаларны башкаргандагы гамәлләренә;

3) законнар белән билгеләнгән эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә бәйрәм итүгә бәйле рәвештә юридик затларның һәм гражданнарның гамәлләренә, пиротехник чаралар куллану гамәлләреннән тыш;

*(3 пункт 2013 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәдәни чаралар (шул исәптән тамашалы мәдәни чаралар, рәсми физкультура һәм спорт чаралары) үткәрүгә бәйле гамәлләргә, шулай ук гомумфедераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге күренекле вакыйгаларны бәйрәм итүгә бәйле рәвештә массакүләм чаралар уздыруга бәйле гамәлләргә;

*(4 пункт 2017 елның 22 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында административ җаваплылык билгеләнгән гамәлләргә.

2 статья. **Төнге вакыт**

Әлеге Закон максатларында төнге вакыт дигәндә эш көннәрендә – 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр, ә ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр вакыт аралыгы аңлашыла.

*(2 статья 2012 елның 17 декабрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгы һәм тынлык тәэмин ителә торган объектлар**

Төнлә гражданнарның тынычлыгы һәм тынлык тәэмин ителә торган объектлар түбәндәгеләр:

1) күпфатирлы һәм индивидуаль торак йортлар, шул исәптән аларда урнашкан гомуми файдалану урыннары;

2) сырхауханәләр, диспансерлар һәм башка медицина оешмалары, шифаханәләр, ял йортлары, пансионатлар, интернаты булган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, балалар, өлкән гражданнар һәм инвалидлар өчен интернат йортлар урыннары;

*(2 пункт 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

3) кунакханәләр номерлары һәм тулай тораkларның торак бүлмәләре;

4) йорт яны территорияләре;

5) кемпинглар, мотельләр, ял базалары территорияләре;

6) бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциячел булмаган дача берләшмәләре территорияләре.



4 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган гамәлләр**

Әлеге Законның 3 статьясында санап үтелгән объектларда төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган түбәндәге гамәлләрне кылу тыела:

1) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп телевизорларны, радиоалгычларны, магнитофоннарны һәм башка тавыш чыгара торган җайланмаларны, шулай ук тавыш көчәйткеч җайланмаларны, шул исәптән транспорт чараларында, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларында һәм күңел ачу үзәкләрендә урнаштырылганнарны куллану;

2) берничә мәртәбә эшләп киткән саклау сигнализациясенең тавыш сигналларын вакытында сүндермәү, шул исәптән транспорт чараларында урнаштырылганнарын да, йә төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп төзек булмаган саклау сигнализациясен куллану;

3) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп пиротехник чараларны куллану;

4) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп музыка коралларында уйнау, кычкырулар, сызгыру, җырлау, шулай ук тавыш чыгара торган бүтән гамәлләр;

5) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләрен башкару.

5 статья. **Административ җаваплылык**

Әлеге Закон нигезләмәләрен бозуда гаепле затлар Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә җаваплы булалар.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль
2010 елның 12 гыйнвары
№ 3-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында

*(2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы,*
*2005 елның 10 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы,*
*2011 елның 12 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы,*
*2012 елның 30 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы,*
*2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы,*
*2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы,*
*2017 елның 5 июлендәге 49-ТРЗ номерлы*
*Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

Әлеге Закон торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торакка конституциячел хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

*(преамбула 2005 елның 10 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме – торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак бинасы сатып алуда, төзүдә яисә аны реконструкцияләүдә дәүләт ярдәме;

яшь гаилә – законнар нигезендә теркәлгән никахтан соң баштагы өч елдагы гаилә (гаиләдә бала булган очракта – никахның дәвамлылыгына бәйсез рәвештә), ул гаиләдә ир белән хатынның берсе – 30 яшькә җитмәгән, ә балалы тулы булмаган гаиләләр өчен – ана яисә ата 30 яшькә җитмәгән булырга тиеш;

вәкаләтле дәүләт органы – әлеге Закон нигезендә дәүләт ярдәме гамәлләренең дәүләт заказчысы буларак, дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

*(2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*



вәкаләтле оешма – вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме гамәлләрен үтәүче итеп билгеләнүче коммерциячел булмаган оешма.

*(абзац 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

1[1] статья. **Вәкаләтле оешманың эшчәнлек тәртибе**

*Беренче өлеш үз көчен югалтты. – 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

Вәкаләтле оешма вәкаләтле дәүләт органы белән җирле үзидарә органнары арасында төзелүче шартнамәләр нигезендә эш итә, әлеге шартнамәләрдә торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме гамәлләрен үтәү буенча якларның үзара хокуклары һәм бурычлары билгеләнә.

*(икенче өлеш 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Вәкаләтле оешма шартнамә яклары исеменнән яшь гаиләләр белән торак бинаны сату-алу, алмаштыру турында шартнамәләр, торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү гамәлләрен үтәү кысаларында бүтән төрле шартнамәләр төзи, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның буенча алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алганда законнарда билгеләнгән тәртиптә катнаша.

*(статья 1[1] 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

2 статья. **Дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Торак шартларын яхшыртканда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар белән җайга салына.

3 статья. **Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәменең рәвешләре**

Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме кире кайтарулы, ташламалы, вакытлы нигезләрдә түбәндәге рәвешләрдә күрсәтелә:

яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү;

яшь гаиләнең торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүен тәэмин итү.

4 статья. **Дәүләт ярдәме күрсәтү өчен нигезләр**

Дәүләт ярдәме законнар нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә күрсәтелә.

5 статья. **Дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул итү тәртибе**

Дәүләт ярдәме алу өчен яшь гаилә яшәү (теркәлү) урыны буенча җирле үзидарә органына тиешле гариза белән мөрәҗәгать итә. Гаризага кушылып бирелүче документлар исемлеге, аларны карау тәртибе, шулай ук яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

*(беренче өлеш 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*Икенче өлеш үз көчен югалтты. — 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

Дәүләт ярдәме күрсәтү турындагы карар, дәүләт ярдәме күрсәтү өчен нигезләр булганда, җирле үзидарә органы тәкъдиме буенча, чират тәртибендә вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан кабул ителә. Карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә вәкаләтле дәүләт органы әлеге карар турында яшь гаиләгә хәбәр итә.

*(өченче өлеш 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6 статья. **Дәүләт ярдәмен күрсәтү өчен бүлеп бирелүче финанс чаралары күләме**

*(статья исеме 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Яшь гаиләгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бүлеп бирелүче финанс чараларының күләме торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрына Татарстан Республикасы буенча уртача базар бәясенең Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган күрсәткеченнән һәм ике кешедән гыйбарәт яшь гаилә (яшь парлар яисә бер яшь әти яки әни һәм бер бала) өчен 42 квадрат метр булган, яшь парлардан кала тагын бер яисә аннан күбрәк баланы үз эченә алган өч яисә аннан күбрәк кешедән гыйбарәт яшь гаилә өчен (йә бер яшь әти яки әнидән һәм ике яисә аннан күбрәк баладан гыйбарәт яшь гаилә өчен) бер кешегә 18 квадрат метр булган гомуми мәйданы зурлыгыннан исәпләп чыгарылган торак урын бәясенең 60 процентыннан артмаска тиеш.

*(2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы, 2011 елның 12 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы, 2017 елның 5 июлендәге*



*49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган акчалар әлеге Закон нигезендә яшь гаиләләр белән төзелгән шартнамәләрне дәүләт теркәвенә алуга бәйле чыгымнарга юнәлтелә алмый.

7 статья. **Яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү**

Үзенә карата дәүләт ярдәме күрсәтелү турында карар кабул ителгән яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү граждан законнары нигезендә вәкаләтле оешма белән яшь гаилә арасында төзелүче торак бинаны сату-алу, торак төзелешен өлешләп инвестицияләү яисә торак бинаны алмаштыру шартнамәсе буенча башкарыла.

*(беренче өлеш 2005 елның 10 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Торак бинаны сату-алу һәм торак төзелешен өлешләп инвестицияләү шартнамәсе сатып алына торган торак урыны өчен түләүне 15 елдан да артык булмаган вакытка кичектереп тору, башлангыч кертем түләүнең һәм яшь гаиләнең үз бурычларын үтәүне тәэмин итүенең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Сатып алына торган торак бина өчен яшь гаиләгә түләүне кичектереп торган өчен процентлар алынмый.

*(икенче өлеш 2005 елның 10 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Алмаштыру шартнамәсе буенча яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләгәндә, яшь гаилә аның буенча үзенең торак урынын сатып алына торганына алмаштыру өчен тапшырырга йөкләмә ала, бәяләрдәге аерманы яшь гаилә, процентлар түләмичә генә, түләүне 15 елга кадәр кичектереп тору шартнамәсе нигезендә түли.

Торак бинаны сату-алу, торак төзелешен өлешләп инвестицияләү яисә торак бинаны алмаштыру шартнамәсе буенча башлангыч кертем сатып алына торган торак урыны хакының кимендә 20 проценты күләмендә алына һәм ул акчалата һәм (яисә) яшь гаиләнең милекчелек хокукындагы торак урыны белән гамәлгә ашырыла.

*(дүртенче өлеш 2005 елның 10 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә, өч яшькә кадәрге баласы булган яшь гаилә гаризасы буенча, балага өч яшь тулганчы түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш.

*(7 статья 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

8 статья. **Яшь гаилә өчен торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү**

Яшь гаилә өчен торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү вәкаләтле оешма белән яшь гаилә арасында граждан законнарына туры китереп төзелүче шартнамә нигезендә башкарыла, анда яшь гаиләгә торак урынын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерү өчен кирәк булган товарларны сату, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү каралырга мөмкин.

Торак бинаны төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү турында шартнамә сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен түләүне 15 елдан да артык булмаган вакытка кичектереп тору һәм яшь гаиләнең үз бурычларын үтәүне тәэмин итүенең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен түләүне кичектереп торган өчен процентлар алынмый.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә торак бинаны төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетергәнче түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш, әмма ул вакыт тугыз айдан да артык була алмый.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә, өч яшькә кадәрге баласы булган яшь гаилә гаризасы буенча, балага өч яшь тулганчы түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш.

*(8 статья 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

9 статья. **Йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү**

Әлеге Закон нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәү граждан законнары нигезендә тәэмин ителә.

10 статья. **Дәүләт ярдәмен финанслау**

Дәүләт ярдәмен финанслау чираттагы финанс елына тиешле бюджетларны раслаганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм җирле үзидарә органнары билгели торган күләмнәрдә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар исәбеннән башкарыла. Дәүләт ярдәмен финанслау өчен законнарда тыелмаган башка чыганаклардан да акчалар җәлеп ителергә мөмкин.

*(беренче өлеш 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә; 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабренә кадәр беренче өлешенең гамәлдә булуы туктатылып тора)*



Дәүләт ярдәме өчен бүлеп бирелгән финанс чаралары әлеге Законның 1 статьясының икенче өлешендә күрсәтелгән шартнамә нигезендә максатчыл кулланылалар. Финанс чараларын юнәлдерү һәм куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен җибәрелгән финанс чараларын туплау, исәпкә алу һәм куллану өчен вәкаләтле оешма Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтләр бирелгән банкта махсус счет ача.

Вәкаләтле оешма дәүләт ярдәме өчен бүлеп бирелүче акчаларның максатчыл кулланылышы өчен җаваплы була.

Яшь гаиләләр белән әлеге Закон нигезендә төзелгән шартнамәләрнең шартлары буенча кире кайтарылучы финанс чаралары, шулай ук торак урынын алмаштыру турындагы шартнамәләр буенча вәкаләтле оешма тарафыннан сатып алына торган торак урыннары яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәмен күрсәтүне дәвам итү өчен кулланылалар.

*(10 статья 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

10[1] статья. *Үз көчен югалтты. — 2011 елның 12 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

11 статья. **Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр**

Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) яшь гаилә тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән белешмәләрнең булуы;

2) әлеге Законның 4 статьясында каралган нигезләрнең булмавы.

*(беренче өлеш 2011 елның 12 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту турындагы карар җирле үзидарә органының яисә вәкаләтле оешманың баш тарту нигезләре күрсәтелгән тәкъдиме буенча вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан кабул ителә. Карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә вәкаләтле дәүләт органы әлеге карар турында яшь гаиләгә хәбәр итә.

*(икенче өлеш 2001 елның 27 июнендәге 903 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

12 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән алып өч ай эчендә:

— норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга;

— әлеге Законны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган норматив хокукый актлар эшләргә һәм кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 21 октябре
№ 2443

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Транспорт салымы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2002 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

*(2003 елның 29 июлендәге 23-ТРЗ номерлы,
2003 елның 28 ноябрендәге 48-ТРЗ номерлы,
2004 елның 26 ноябрендәге 57-ТРЗ номерлы,
2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы,
2006 елның 10 февралендәге 4-ТРЗ номерлы,
2006 елның 6 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы,
2008 елның 21 июлендәге 28-ТРЗ номерлы,
2009 елның 26 ноябрендәге 53-ТРЗ номерлы,
2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы,
2014 елның 2 июнендәге 42-ТРЗ номерлы,
2014 елның 11 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы,
2016 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә,
2014 елның 26 мартындагы 19-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы
Законы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)*

*Преамбула үз көчен югалтты. — 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Транспорт салымы (алга таба — салым) Россия Федерациясе Салым кодексы һәм әлеге Закон белән билгеләнә һәм әлеге Закон белән гамәлгә кертелә.

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым ставкалары, салым түләүчеләр — оешмалар тарафыннан аны түләү тәртибе һәм вакытлары, шулай ук салым ташламалары һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләре билгеләнә.

*(икенче абзац 2014 елның 2 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*(1 статья 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2 – 3 статьялар. *Үз көчләрен югалтты. – 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

4 статья. **Салым чоры. Хисап чоры**

1. Салым чоры дип календарь ел таныла.
2. Оешма булып торган салым түләүчеләр өчен хисап чоры итеп беренче квартал, икенче квартал, өченче квартал таныла.

*(4 статья 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5 статья. **Салым ставкалары**

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

*(беренче абзац 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

| **Салым салу объектының исеме** | **Салым ставкасы (сумнарда)** |
|---|---|
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган җиңел автомобильләр (һәр ат көченнән):** | |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп, оешмаларга теркәлгән | 25 |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп, физик затларга теркәлгән | 10 |
| 100 ат көченнән артык, 150 ат көченә кадәр (73,55 кВттан 110,33 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 35 |
| 150 ат көченнән артык, 200 ат көченә кадәр (110,33 кВттан 147,1 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 50 |
| 200 ат көченнән артык, 250 ат көченә кадәр (147,1 кВттан 183,9 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 75 |
| 250 ат көченнән артык (183,9 кВттан артык) | 150 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган мотоцикллар һәм мотороллерлар (һәр ат көченнән):** | |
| 20 ат көченә кадәр (14,7 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 8 |
| 20 ат көченнән артык, 38 ат көченә кадәр (14,7 кВттан 27,95 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 12 |
| 38 ат көченнән артык (27,95 кВттан артык) | 50 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган автобуслар (һәр ат көченнән):** | |
| 200 ат көченә кадәр (147,1 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 50 |
| 200 ат көченнән артык (147,1 кВттан артык) | 100 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган йөк автомобильләре (һәр ат көченнән):** | |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 25 |
| 100 ат көченнән артык, 150 ат көченә кадәр (73,55 кВттан 110,33 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 40 |
| 150 ат көченнән артык, 200 ат көченә кадәр (110,33 кВттан 147,1 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 50 |
| 200 ат көченнән артык, 250 ат көченә кадәр (147,1 кВттан 183,9 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 65 |
| 250 ат көченнән артык (183,9 кВттан артык) | 85 |
| Үзйөрешле башка транспорт чаралары, пневматик һәм чылбырлы йөрешле машиналар һәм механизмнар (һәр ат көченнән) | 25 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган карда йөрү машиналары һәм моточаналар (һәр ат көченнән):** | |
| 50 ат көченә кадәр (36,77 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 25 |
| 50 ат көченнән артык (36,77 кВттан артык) | 50 |

| | |
|---|---|
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган катерлар, моторлы көймәләр һәм су транспортының башка чаралары (һәр ат көченнән):** | |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 50 |
| 100 ат көченнән артык (73,55 кВттан артык) | 100 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган яхталар һәм җилкәнле-моторлы башка суднолар (һәр ат көченнән):** | |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 100 |
| 100 ат көченнән артык (73,55 кВттан артык) | 200 |
| **Двигателенең егәрлеге түбәндәгечә булган гидроцикллар (һәр ат көченнән):** | |
| 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) һәм аны кертеп | 125 |
| 100 ат көченнән артык (73,55 кВттан артык) | 250 |
| Тулаем сыйдырышлылыгы билгеләнә торган үзйөрешсез (буксирдагы) суднолар (тулаем сыйдырышлылыгының һәр регистр тоннасыннан) | 100 |
| Двигательле самолетлар, вертолетлар һәм башка һава суднолары (һәр ат көченнән) | 125 |
| Реактив двигательле самолетлар (тарту көченең һәр килограммыннан) | 100 |
| Двигательләре булмаган башка су һәм һава транспорты чаралары (транспорт чарасы берәмлегеннән) | 1000 |

*(5 статья 2009 елның 26 ноябрендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6 статья. **Салым ташламалары**

1. Түбәндәгеләр исеменә теркәлгән транспорт чаралары салым салудан азат ителә:

1) Чернобыль фаҗигасе аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнар категориясе, «Чернобыль АЭСындагы



фаҗига аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә, шулай ук аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре;

*(1 пунктча 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2) Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының өч дәрәҗәсе белән бүләкләнгән гражданнар һәм Хезмәт Даны орденының өч дәрәҗәсе белән бүләкләнгән гражданнар;

*(2 пунктча 2003 елның 28 ноябрендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) милкендә 110 ат көченә кадәр егәрлектәге двигательле (80,91 кВтка кадәр) автомобиле булган Бөек Ватан сугышы инвалидлары, анда катнашучылар һәм Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан төзелгән концлагерьларның, геттоның, башка мәҗбүри тоту урыннарының балигъ булмаган элеккеге тоткыннары;

*(3 пунктча 2004 елның 26 ноябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде; 2008 елның 21 июлендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) милкендә 100 ат көченә кадәр (73,55 кВтка кадәр) егәрлектәге двигательле автомобиле булган I һәм II төркем инвалидларга.

*(6 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктча нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституция судының 2014 елның 3 июлендәге 59-П номерлы карары белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танылды; 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызып чыгару аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» Федераль закон нигезендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнар категориясенә теркәлгән су-һава юллары транспорт чаралары салым салудан азат ителәләр.

3. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2005 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән шартнамәләр буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы салым түләүчеләр салым түләүдән азат ителәләр.

*(беренче абзац 2006 елның 6 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Татарстан Республикасының Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәга-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары транспорт чарасын исәпкә алу вакытыннан 10 ел эчендә салым салынудан азат ителәләр.

*(икенче абзац 2006 елның 10 февралендәге 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде; 2014 елның 11 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Әлеге Законның 5 статьясында каралган салым ставкаларыннан 50 процент күләмендә ташлама түбәндәгеләргә карата билгеләнә:

1) Россия Федерациясендә җитештерелгән һәм кимендә ЕВРО-2 экологик нормаларына туры килә торган двигательләр белән җиһазландырылган, лизинг бирүче балансында тора торган һәм лизингка кимендә бер елга  тапшырылган, двигателенең куәте 150 ат көченнән югарырак булган йөк автомобильләренә, автобусларга;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыручы һәм гаскәр тибындагы автомобиль колонналарын төзүгә һәм тотуга мобилизацион йөкләмәләр бирелгән оешмалар милкендә булган гаскәр тибындагы автомобиль колоннасы составына кертелгән автобусларга. Ташлама транспорт чаралары гаскәр тибындагы автомобиль колоннасы составында булган чорга бирелә.

*(4 пункт 2016 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5. Ике һәм аннан күбрәк транспорт чарасы теркәлгән физик затлар өчен ташлама үзе сайлап алган бер транспорт чарасына бирелә.

*(5 пункт 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. Календарь ел дәвамында өстенлекле ташламага хокук барлыкка килгәндә салымны яңадан санау әлеге хокук барлыкка килгән айдан алып башкарыла.

*(6 пункт 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

7 статья. *Үз көчен югалтты. – 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*



8 статья. **Салым түләүчеләр – оешмалар тарафыннан салым һәм салым буенча аванс түләүләре тәртибе һәм вакыты**

*(статья исеме 2014 елның 2 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1. Оешмалар булып торган салым түләүчеләр салым буенча аванс түләүләрен хисап чорыннан соң килгән икенче айның 10 нчы числосыннан соңга калмыйча башкаралар.

Оешмалар булып торган салым түләүчеләр салым чоры узганнан соң түләргә тиешле салым салым чоры узганнан соңгы елның 10 февраленнән соңга калмыйча түләнә.

2. *Үз көчен югалтты. – 2014 елның 2 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.*

*(8 статья 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч, ләкин салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль
2002 елның 29 ноябре
№ 24-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында физик затлар мөлкәтенә 2016 елгы салым чорында түләнергә тиешле салым буенча недоимка суммасына пеня исәпләнә башлау датасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 75 статьясының 4.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасында физик затлар мөлкәтенә 2016 елгы салым чорында түләнергә тиешле салым буенча недоимка суммасына пеня 2018 елның 1 июленнән башлап исәпләнә дип билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2017 елның 22 декабре
№ 96-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге закон Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә региональ салымнар буенча недоимка, шушы салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгели.

2 статья. **Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр**

2017 елның 1 гыйнварына региональ салымнар буенча недоимка, шулай ук әлеге салымнар буенча түләнүгә ышанычсызлыкны тану турында карар кабул ителү датасына саналган, аерым салым түләүчеләргә исәпләнелгән, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләнү мөмкин булмаган пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсыз дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

2) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган региональ салымнар буенча оешмаларда яисә индивидуаль эшкуарларда исәпләнелә торган недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу;

3) салым исәбенә куелган һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында үзләренә карата мәгълүмат булмаган оешмаларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

4) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлеге тәмамлану турында башкаручы суд приставының карары чыгарылуга бәйле рәвештә салым органнары тарафыннан түләтү мөмкин булмаса һәм, әгәр недоимка һәм (яисә) пенялар һәм штрафлар буенча бурычы барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт үтсә, бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда тормаган физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

5) оешмаларның пенялар исәпләнә торган недоимкасы булмаганда, әлеге недоимканы түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән пенялар буенча бурычы булу.

3 статья. **Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар**

Әлеге Закон кушымтасы нигезендә региональ салымнар буенча недоимка, шушы салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеген расларга.

4 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2017 елның 19 июле
№ 54-ТРЗ

«Региональ салымнар буенча недоимка,
пенялар һәм штрафлар буенча бурыч
түләнүгә ышанычсызлыкны тануга
өстәмә нигезләр билгеләү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Региональ салымнар буенча недоимка, әлеге салымнарга пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар исемлеге

1. Әлеге Законның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

2) физик затның үлү фактын физик затларның граждан хәле актларын теркәүче орган тарафыннан теркәү турында Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясындагы 3 пункты нигезендә салым органына кергән белешмәләр;

3) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы).

3. Әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) оешманы исәпкә алу урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) юридик зат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында мәгълүматның булмавы хакында теркәүче орган белешмәсе.

4. Әлеге Законның 2 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

1) физик затның яшәү урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар, штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

2) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча түләтүчегә башкару документы кире кайтарылганда башкару эшчәнлегенең тәмамлануы турында башкаручы суд приставы карарының күчермәсе;

3) физик затның бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда тормавы турында салым органы белешмәсе.

5. Әлеге Законның 2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, — оешманы исәпкә алу урыны буенча салым органының пенялар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе.